ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 7** **от 17 ноябрь 2023 ел.**

«Ютазы муниципаль районының
Кәрәкәшле авыл җирлегенең
2024 елга һәм 2025-2026 еллар
план чорына бюджеты турында»
карар проекты буенча гавами
тыңлауларны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 2023 елның 31 маендагы 8 номерлы карары нигезендә

**КАРАР ИТӘМ:**

1. «Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджеты турында» карар проекты буенча 2023 елның 04 декабренә 13.00 сәгатьтә Кәрәкәшле авылы, Сирин Батыршин ур., 33 йорт адресы буенча авыл җирлеге бинасында гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетына:

2.1. «Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджеты турында" Совет карары проектын Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
2.2. «Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджеты турында» хисап проекты буенча түбәндәге адрес буенча тәкъдимнәр җыярга: Кәрәкәшле авылы, Сирин Батыршин ур., 33 йорт, Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты.
2.3. “Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2024 елгы һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турында карар проекты буенча тәкъдимнәрне өйрәнү һәм гомумиләштерү эшен оештырырга, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, «Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турында»

карар проектын эшләп бетерергә һәм Кәрәкәшле авыл җирлеге Советына җибәрергә.

3. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында.

Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башлыгы: А. Г. Дәүләтгәрәев